Туган телгә мәхәббәт уяту, укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү максатыннан гимназиябездә театр түгәрәге актив эшчәнлек алып бара. Үзләренең спектакльләре белән район, республика сәхнәләрендә чыгыш ясыйлар. 28нче гыйнвар көнне гимназиянең “Маска” коллективы Саба районында үткәрелгән Шәүкәт Биктимеров исемендәге балалар театр сәнгатенең зона бәйгесендә 1 нче урын яулады. Алар Г.Гыйльмановның “Убырлы карчык, Шүрәле һәм Гөлүсә” исемле спектаклен сәхнәләштерде.





